КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1247

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче. 2020 ел, 14 май, 389 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2013 - 2020 елларга» сүзләрен «2013 - 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктта «грантларны гамәлгә куючы» сүзләрен «түләүләрне гамәлгә куючы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибендә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт ярдәме авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм (яисә) кулланучылар кооперациясе оешмаларында югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары тәмамланганнан соң эшләүче яшь белгечләргә, югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына, аграр юнәлештәге мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның

кече фәнни хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителгәнче 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килү шартларында бирелә:

Россия Федерациясе гражданнары булу;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Түләүләр алу өчен яшь белгеч (алга таба - гариза бирүче) эшкә урнаштырылган көннән алып алты айдан да артык булмаган вакытта Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

шул исәптән мөрәҗәгать итүчегә карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәве турында мәгълүматны үз эченә алган түләүләр бирү турында гариза (ирекле форма);

авыл хуҗалыгы оешмасы яисә кулланучылар кооперациясе оешмасы белән төзелгән хезмәт шартнамәсенең күчермәсе;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсе;

эшкә кабул итү турында боерык күчермәсе;

мәгариф турында диплом күчермәсе кушымтасы белән (дипломга кушымта);

тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $^{6}$61 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар;

хәрби бурычлылар өчен хәрби билет күчермәсе;

Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе;

Түләүләр алу өчен Идарәгә тапшырыла торган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы оешмасы һәм (яисә) кулланучылар кооперациясе оешмасы тарафыннан таныклана.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Идарә:

«Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасына кергән көнне түләүләр бирү турында гаризаларны теркиләр;

түләүләрне бирү турында гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә әлеге Тәртипнең 3 пунктына туры килү-килмәү өчен тапшырылган документларны карыйлар һәм түләү бирү яисә түләүне бирүдән баш тарту турында карар кабул итәләр;

түләүләрне бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә гариза бирүче белән килешү төзиләр;

килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча гариза бирүчеләргә түләүләрне күчерү өчен җыелма белешмә-исәп төзиләр;

белешмә-исәп төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә аны Министрлыкка җибәрәләр.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

гариза бирүченең түләүләрне алуга кабат мөрәҗәгате;

түләүләр алучы тарафыннан документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау) һәм (яисә) тапшырылган документларныңэ әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

түләүләрне алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.»;

түләүләрне алучының әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве.

Түләүләр бирүдән баш тарткан очракта Идарә әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә, тиешле нигезләрне күрсәтеп, гариза бирүчегә түләүне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Кирәк булганда Идарә Министрлык билгеләгән форма нигезендә гариза бирүче белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счеттан алучылар исәбенә Татарстан Республикасы муниципаль районына тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-хисаплар тапшырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетының акчаларын күчерә һәм акчалар күчерүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган Идарәләрнең шәхси счетларына китерә.

Идарә бюджет акчаларын үз шәхси счетына алган көннән алып биш көн эчендә түләүләр алучыларның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына акча күчерә.»;

8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктта:

өченче абзацка «, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве стипендия түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

10 пунктта:

өченче абзацка «, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве стипендия түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

11 пунктта:

икенче абзацка «, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве стипендия түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

12 пунктта:

икенче абзацка «кеше» сүзеннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве стипендия түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

түбәндәге эчтәлектәге $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Әлеге Тәртипнең 4, 9 - 12 пунктларында күрсәтелгән түләүләрне алучыларга документларны биргән көндә үз инициативалары белән салым түләүче (салым түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр үтәлү турында белешмә тапшырырга. Әгәр күрсәтелгән документ түләүләрне алучы тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә салым органыннан соратып ала.»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы гаилә фермер династиясе» республика конкурсында җиңүчеләргә - крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына премияләр түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар бирү тәртибендә:

2.3 пунктның 2.3.2 пунктчасындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КФХ салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел.»;

4.3 пунктның 4.3.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.6. Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе;»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалыгы» республика конкурсын уздыру тәртибенең 4.4 пунктындагы 4.4.8.8 пунктчасында «шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның салымнар, җыемнар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмауны раслаучы» сүзләрен «салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен түләү йөкләмәсен башкару турында,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыгының иң яхшы башлыгы» республика конкурсын уздыру тәртибенең 4.4 пунктындагы 4.4.10 пунктчасында «(КНД буенча 1120101 коды формасы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының иң яхшы рәисе» республика конкурсын уздыру тәртибендә:

2.2 пунктның сигезенче абзацында «2017 ел» сүзләрен «2007 ел» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктының 4.4.9 пунктчасында «(КНД буенча 1120101 коды формасы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында кече хуҗалыкларны үстерү буенча авыл җирлегенең иң яхшы башлыгы» республика конкурсын уздыру тәртибенең 4.4 пунктындагы 4.4.8.8 пунктчасында «авыл җирлеге башлыгының үтәлмәгән булуын раслый торган» сүзләрен «салым түләүче (җыемы түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан башкару турында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин